**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Каенсар торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“11” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Каенсар торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Каенсар торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк граждannardan, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән граждannar һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз)сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-насос торбаларын сатып алу һәм алыштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

- скважина өчен су асты насосын сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Каенсар авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Каенсар авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.